**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА ЛАИШЕВО**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Коммунальная, д.3,
г.Лаишево,422610

Коммунальная ур., 3 нче йорт,
Лаеш ш.,422610

тел: 8-(84378) -2-57-77, факс: 8-(84378) -2-50-62, e-mail:Gorod.La@tatar.ru

2025 елның «3» декабре 22 номер

# КАРАР

**16:24:170134:656 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы боерыгы проектын карау буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 һәм 39 статьялары, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре " муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы нигезендә, Территориянең тотрыклы үсешен, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураларны үстерүне тәэмин итү, гражданнар һәм аларның берләшмәләре мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенең 2025 елның 1 декабрендә 10021/исх. номерлы мөрәҗәгате нигезендә, Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре башкарма комитеты КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, "Лаеш шәһәре" муниципаль берәмлеге, Лаеш шәһәре, Ленин ур., 32а йорт адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы "Лаеш шәһәре" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре азкатлы торак төзелеше зонасында (Ж2),кадастр номеры 16:24:170134:656., мәйданы 1986 кв. м булган җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән "иҗтимагый туклану" төренә рөхсәт бирү буенча Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы карары проектын карау буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Гавами тыңлаулар үткәрү чорын – кызыксынучы затларга аларны үткәрү турында хәбәр иткән вакыттан алып гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр билгеләргә.

3. Эшче комиссиягә 16:24:170134:656 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы боерыгы проектын карау буенча гавами тыңлауларны оештыруда һәм уздыруда әзерлек үткәрергә.

1.1. Гавами тыңлаулар башлану турында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 маддәсендә каралган хәбәр әзерләргә;

1.2. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көннән алып ике эш көне эчендә Татарстан Республикасында җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясенә, карар кабул итү өчен документлар комплекты кушып, хәбәр итәргә кирәк.

4. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http:// laishevo.tatarstan.ru/publichnoe-obsuzhdenie-5676969.htm веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **В.А. Арефьев**